ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.09.2019 № 891

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2007 елның 2 мартындагы 101номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 342-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 августындагы 283-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Нурлат шәһәре прокуратурасының 13.09.2009 ел, 02-08-01-2019/147 номерлы протестын үтәү йөзеннән, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Капиталь һәм индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүгә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 елның 2 мартындагы 101 номерлы карары белән расланган «Капиталь һәм индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүгә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү тәртибе»нә рөхсәт алу өчен документлар исемлеге»нең 2.5 пунктына үзгәрешләр кертергә, 2.5.1 пунктының 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

а) аңлатма язуы;

б) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир кишәрлеген планлаштыру схемасы, ә линия объектларына карата проект документациясе әзерләнгән очракта, территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган бүлеп бирү полосасы проекты (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру документациясен әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш);

в) архитектура һәм конструктив карарлар булган бүлекләр, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керә алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарлар һәм чаралар (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге башка объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына карата проект документларын әзерләү очрагында);

г) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү, башка капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен аларның өлешләрен сүтү кирәк булган очракта, капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү эшләрен оештыру проектын да кертеп);

д) күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелгән һәм Кодексның 57.3 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очракта җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы бирелгән җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен территориянең кадастр планында урнаштыру схемасы. Әгәр җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм өченче затларның хокуклары белән йөкләнмәгән җирләрдән һәм (яки) җир кишәрлекләреннән, сервитуттан, ачык сервитуттан тыш барлыкка килә, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү, җир законнары нигезендә, территорияне ызанлау проекты һәм (яки) территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы нигезендә, җир кишәрлеге төзелгәнче рөхсәт ителә.

е) капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору эшләре җирле үзидарә органы тарафыннан төзелгән территорияне үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта, төзелгән территорияне үстерү турында килешү яки территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә күчермәсе (территорияне комплекслы үстерүне мөстәкыйль гамәлгә ашыру турында карар кабул ителгән очрактан тыш).

Әлеге документ вәкаләтле орган тарафыннан, әгәр төзүче әлеге документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырмаган булса, төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза алынганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына караган оешмаларда вәкаләтле орган тарафыннан соратып алына.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов